# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлеге составына керүче Мөкерле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

17.11.2025 № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Мөкерле авыл җирлегенең Мөкерле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; Мөкерле авылында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү өчен түләүгә Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2025 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 283 катнашучы кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 145 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 145 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлегенең Мөкерле авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Мөкерле авыл җирлегенең Мөкерле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; Мөкерле авылында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү өчен түләүгә Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Мөкерле авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: _________ С.Н. Тюплина

Мөкерле авыл җирлеге
башлыгы _________________ С.Н. Тюплина